КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 декабрь г.Казань № 1665

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 6 декабрь, 570 нче карары белән расланган Гражданнарга бер тапкыр бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм вакцинациядән соң өзлеккәндә айлык акчалата компенсацияләр түләү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданнарга бер тапкыр бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм вакцинациядән соң өзлеккәндә айлык акчалата компенсацияләр түләү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2005 ел, 6 декабрь, 570 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 21 май, 330 нчы; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2018 ел, 3 август, 630 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданнарга бер тапкыр бирелә торган дәүләт пособиеләрен һәм вакцинациядән соң өзлеккәндә айлык акчалата компенсацияләр түләү вәкаләтләрен тормышка ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта татар текстында «субвенцияләр» сүзеннән соң «(алга таба – субвенцияләр)» сүзләрен өстәргә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Федераль бюджеттан бирелә торган субвенцияләр Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә (алга таба – Казначылык) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына ачылган Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетына керә.»;

4 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

5 һәм 6 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылыктан бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм финанслауның иң чик күләмнәре турында мәгълүмат алган көннән биш эш көне эчендә агымдагы финанс елына финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына (алга таба – Министрлык) аның заявкалары буенча җиткерә.

6. Министрлык, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан агымдагы финанс елына финанслауның иң чик күләмнәре җиткерелгән көннән биш эш көне эчендә гражданнарның кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына алга таба күчерү өчен агымдагы финанс елына финанслауның иң чик күләмнәрен «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенә (алга таба – Үзәк) җиткерә.»;

$6^1$ пунктта «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау» сүзләрен төшереп калдырырга, татар текстында «министрлыгына» сүзен «Министрлыкка» сүзенә алмаштырырга;

7 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау» сүзләрен төшереп калдырырга, татар текстында «министрлыгына» сүзен «Министрлыкка» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 9 – 11 пунктлар өстәргә:

«9. Агымдагы финанс елында субвенцияләрнең файдаланылмый калган өлеше Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә федераль бюджет керемнәренә кире кайтарылырга тиеш.

10. Министрлык һәм Үзәк тапшырыла торган хисап мәгълүматлары дөрес булмаган һәм субвенциядән максатчан файдаланмаган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

11. Субвенциядән максатчан файдалануны контрольдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин